Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге Советы

Богородский авыл җирлеге башлыгы
КАРАРЫ

10 февраль, 2026 ел № 6

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 1743 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында» 2023 елның 29 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы карарының 4.2 пункты, Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 80 номерлы карары белән расланган нигезләмә (2017 елның 14 декабрендәге 94 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 108, 2019 елның 2 октябрендәге 156 номерлы, 2022 елның 12 декабрендәге 62 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 70 номерлы үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләренең һәм капиталь төзелеш объектларының тормыш эшчәнлеге, хокук ияләренең һәм законлы мәнфәгатьләренең уңай шартларына район халкының хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләргә.

2. Генераль планга үзгәрешләр кертү проекты буенча гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына йөкләргә.

3. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Богородский авыл җирлеге башкарма комитетына гавами тыңлауларны оештыручыга җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 20 февраленнән дә соңга калмыйча тәмамланырга тиешлеген билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Богородский авыл җирлеге башлыгы Д.Ю. Булыгин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОГОРОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ